РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2020 елның 15 гыйнвары г. Буа шәһәре 7 /ИК-п номерлы

Педагогик хезмәткәрләргә –
яшь белгечләргә ай саен
стимуллаштыручы өстәмә
түләү билгеләү хакында

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә дәүләт ярдәме күрсәтү һәм педагогик кадрларны беркетү максатларында, 2018 елның 29 декабрендәге 1270 номерлы «Педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү билгеләү турында»гы ТР Министрлар Кабинеты карарына таянып, Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмаларында эшләүче педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә ай саен стимул бирә торган өстәмә түләүне, уку йөкләнеше күләменә пропорциональ рәвештә 1 111 сум күләмендә, эшләнгән вакыт күләменә, әмма бер педагог - яшь белгечкә 1 111 сумнан да артмаган күләмдә билгеләргә.

2. Расларга:

Татарстан Республикасы муниципаль мәгариф оешмаларында эшләүче педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан ТР Буа муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе (кушымта).

3. Әлеге карар 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә һәм Татарстан Республикасының официаль хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталының мәгълүмати-телекоммуникацион интернет челтәрләрендә http://buinsk.tatarstan.ru. Адреслары буенча урнаштырылырга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары - «Буа муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ начальнигы И. Ф. Ханбикова йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.Р. Камартдинов

ТР Буа муниципаль районы
Башкарма комитетеның
«15» гыйнвары 2020 елның
7 /ИК-п номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы муниципаль мәгариф оешмаларында эшләүче педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан ТР Буа муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы муниципаль белем бирү оешмаларында эшләүче педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү механизмын билгели (алга таба - башка бюджетара трансфертлар).

2. Башка бюджетара трансфертлар тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә, әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы бюджетына бирелә.

3. Әлеге Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет ассигнованияләренең баш бүлүчеләре – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы ( алга таба- Тармак министрлыклары).

4. Башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы бюджетыннан ТР Буа муниципаль район бюджетына, аның территориясендә урнашкан муниципаль мәгариф оешмалары педагогик хезмәткәрләренә- яшь белгечләргә бирелә.

5. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районына бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$Si = D \times k \times 12 \times e,$$

монда:

Si - ТР Буа муниципаль районына, хезмәткә түләү буенча түләүләргә исәпләүләрне исәпкә алып, башка бюджетара трансфертлар күләме, сум;

D - ТР Буа муниципаль районы территориясендә урнашкан оешмада эшләүче педагогик хезмәткәр- яшь белгечкә ай саен 1 111 сум күләмендә стимуллаштыручы өстәмә түләү;

12 - елда айлар саны;

$k_i$ - ТР Буа муниципаль районы территориясендә урнашкан оешмаларда эшләүче педагогик хезмәткәр- яшь белгечләнең планлы саны;

e - законнар нигезендә бюджеттан тыш фондларга иминият взнослары күләме.

6. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районына тиешле финанс елына башка бюджетара трансфертлар күләмен бүлү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы белән раслана.

7. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба - җирле үзидарә органы) агымдагы елның 1 февраленә кадәр башка бюджетара трансфертлар алу өчен тармак министрлыкларына түбәндәге документларны тапшыра:
Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы мәгариф оешмаларында эшләүче педагогик хезмәткәрләргә-яшь белгечләргә муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты карары белән расланган, татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар исәбеннән ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү тәртибе;

тармак министрлыклары тарафыннан расланган форма буенча башка бюджетара трансфертлар бирү турында гариза;

муниципаль берәмлек бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү турында гаризага кул куйган затның вәкаләтләрен раслый торган документ;

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмаларында эшләүче педагогик хезмәткәрләр - яшь белгечләрнең тармак министрлыклары боерыклары белән расланган форма буенча реестрлары;

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы бюджетында муниципаль белем бирү оешмаларында эшләүче педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләүләр өчен акча булуын раслаучы документ.

8. Тармак министрлыклары әлеге Тәртипнең 7 пунктында күрсәтелгән документларны, алар кергән көннән, эш көннәрендә исәпләнгән 10 көнлек срокта карый.

Җирле үзидарә органы әлеге Тәртипнең 7 пунктында күрсәтелгән документларның тулы булмаган пакетын яки әлеге Тәртипнең 7 пункты таләпләренә туры килми торган документларны тапшырган очракта, тармак министрлыклары документларны кире кайтаралар һәм биш көн эчендә, кире кайтару сәбәпләрен күрсәтеп, җирле үзидарә органнарына документлар пакетын кире кайтару турында хәбәр итәләр.

Җирле үзидарә органы документлар пакетын кире кайтару турында хәбәрнамә алган көннән өч көн эчендә әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләрне үтәү шарты белән, әлеге Тәртипнең 7 пунктында күрсәтелгән документларны кабат тапшырырга хокуклы.

9. Тармак министрлыклары әлеге Тәртипнең 7 пунктында күрсәтелгән документларны кабат эш көннәрендә исәпләнгән 10 көнлек срокта, алар кергән көннән карый.

10. Башка бюджетара трансфертлар тармак министрлыклары һәм җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган башка бюджетара трансфертлар (алга таба - килешү) турындагы килешү нигезендә бирелә.

Килешү, тармак министрлыклары тарафыннан билгеләнгән таләпләргә туры килә торган, тармак министрлыклары тарафыннан расланган форма буенча бирелгән документларны караганнан соң, эш көннәрендә исәпләнелә торган 10 көнлек срокта төзелә.

11. Тармак министрлыклары квартал саен Федераль казначылыкның территориаль органында ачылган Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы бюджетының шәхси счетына башка бюджетара трансфертларны күчерәләр.

12. Җирле үзидарә органы, әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә, тармак министрлыкларына, хисап кварталыннан соң килүче айның 20 числосына кадәр, педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләүгә башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисап бирә.

13Җирле үзидарә органы һәм аның вазыйфаи затлары закон нигезендә тапшырыла торган хисап белешмәләренең дөрес булмавы һәм башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланмау өчен җаваплы.

14. Әлеге Тәртип нигезендә бирелгән башка бюджетара трансфертларның максатчан кулланылышын контрольдә тоту законнарда каралган тармак министрлыклары һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

15. Җирле үзидарә органының башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланмавы Татарстан Республикасы бюджетыннан закон нигезендә алынган акчалар суммасын бәхәссез түләтүгә китерә.

16. Тармак министрлыкларының әлеге Тәртип нигезендә бирелгән, хисап финанс елында файдаланылмаган башка бюджетара трансфертларга ихтыяҗ булу турындагы карары

нигезендә күрсәтелгән башка бюджетара трансфертлар калдыгыннан артмаган күләмдә акчалар агымдагы финанс елында ТР Буа муниципаль районы бюджеты керемenә кайтарылырга мөмкин, аңа элек бирелгән булсалар, күрсәтелгән башка бюджетара трансфертларны бирү максатларына туры килә торган күләмдә ТР Буа муниципаль районы бюджеты чыгымнарын финанс белән тәэмин итү өчен какйтарылырга мөмкин.

Башка бюджетара трансфертларның файдаланылмаган калдыгы Татарстан Республикасы бюджеты керемenә күчерелмәгән очракта, күрсәтелгән акчалар, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә, Татарстан Республикасы бюджеты керемenә алынырга тиеш.

Татарстан Республикасы муниципаль мәгариф оешмаларында эшләүче педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан ТР Буа муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә кушымта

Педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләүгә башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында
хисап

Муниципаль берәмлек______________________________________________________

| Функциональ чыгымнар статьясы коды | Педагогик хезмәткәрләр - яшь белгечләр саны, кеше | Педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләүләр түләүгә финансланган, сум | | | Өстәмә түләү чыгымнары (хисап чорында ел башыннан алып арта баручы нәтиҗә белән исәпләнгән акча күрсәтелә), сум | | | Файдаланылмаган акча калдыгы, сум | | | Айлык стимуллаштыручы өстәмәләренең уртача күләме (иминият кертемнәрен исәпкә алып) графаның 6/ графасы 2/ саны хисап чорын |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | барлыгы | шул исәптән | | барлыгы | шул исәптән | | барлыгы | шул исәптән: | | |
| | | | айлык стимуллаштыра торган өстәмә түләүне гамәлгә ашыру | бюджеттан тыш дәүләт фондларына иминият взносларын түләү | | айлык стимуллаштыра торган өстәмә түләүне гамәлгә ашыру | бюджеттан тыш дәүләт фондларына иминият взносларын түләү | | айлык стимуллаштыра торган өстәмә түләүне гамәлгә ашыру | бюджеттан тыш дәүләт фондларына иминият взнослары | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| 0701 мәктәпкәчә белем бирү | | | | | | | | | | | |
| 0702 гомуми белем бирү оешмала | | | | | | | | | | | |
| 0703 Балаларга өстәмә белем бирү оешмала | | | | | | | | | | | |
| Барлыгы | | | | | | | | | | | |

Җитәкче ________________________

Баш бухгалтер_______________________

Башкаручы_______________________ телефон номеры